**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

22 сентябрь 2020 ел №4

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүне әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында 2020 елның 20нче июлендәге, № 236-ФЗ Федераль законның 1 статьясындагы 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Апас шәһәр җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Апас шәһәр җирлегенең керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Апас шәһәр җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 10 сентябрендәге N138/3 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.6 пунктана түбәндәге эчтәлекле унберенче абзац өстәргә:

« муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә инициативалы проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча.».

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны "Апас шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары Н.Т. Исмәгыйлевка йөкләргә.

**«Апас шәһәр тибындагы поселогы»**
**муниципаль берәмлек Башлыгы**
**Апас шәһәр җирлеге**
**Советы рәисе Р.Ф. Хисамутдинов**